КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 708

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясендә «Лаеш» индустриаль паркын төзү турында

Татарстан Республикасының сәнәгать инфраструктурасы объектлары үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясендә «Лаеш» индустриаль паркын төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.
2. «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятен төзелә торган «Лаеш» индустриаль паркының идарә итүче компаниясе буларак билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин